

Без бик катлаулы вакытта яшибез; кешеләргә еш кына торле проблемалар, шул исәптән эшкә урнашу проб-лемасы белән очрашырга туры килә. Ярый әле кеше берничә белгечлек яки кvпторле кvнекмәләр иясе булса. Бу очракта барлыкка килгән мәсьәләне хәл итәргә анын һонәре ярдәм итә ала. Шундый очрак турында язмабыз да, дип хикәяли «Призыв» гәжите корреспонденты Елена Севастьянова. Альберт Равил улы Батршин Ләмберәдә туып vскән. Биредә Беренче мәктәпне тәмамлый, аннары Н.П.Огарев исемендәге Мордовия дәvләт университетында социаль хезмәткәр белгечлеге ала. Район хәрби комиссариатында эшли. Барысы да яхшы булыр иде, тик тугыз ел эш стажыннан сон Ләмберә районы комиссариатында vзгәртеп кору эшләре горләде: оч хәрби комиссариатны - Березникнын, Кочкуровонын һәм Ләмберәнен бергә берләштерделәр. Ботен штат диярлек, кыскартуга эләгә. Һәм шул очракта кыскартылган белгечләргә кая барырга, нәрсә эшләргә кала? Ә Альберт Равил улынын гаиләсе, кызы биш яшьтә генә. Тиз генә бер урыннан икенчесенә «сикерергә» яше дә унсигез тvгел инде. Менә шунда туганнарынын берсе ана гасырдан-гасырга нәселле умартачылар булган гаиләсе тарихын искә тошерә. Үзегез уйлап карагыз: Октябрь революциясенә кадәр vк Ләмберәдә яшәvче бабасынын бабасы - Идрис Сафиулла улы һәм әбисенен әбисе - Хафизә Хәлим кызы Фазловлар умарта тотканнар. Бу ерак 1914 елга туры килә. Алардан умартачылыкны бабасы – Рәстәм Идрис улы һәм әбисе - Сафура Ибраһим кызы Фазловлар кабул итә. Аннары умартачылыкны Равилнын әнисе - Румия Рәстәм кызы Батршина дәвам итә. Остәвенә, умарталар һәрвакыт бер урында гына урнашкан да була - бабалардан мирас итеп калган Октябрь урамындагы жир кишәрлегендә. Бал кортлары очен анда иркен, нектар жыярга бар шарлар да тудырылган: янәшәдә басу-болыннар, урман. Боларнын барысын да искә алып, Альберт Равил улы да vз кочен яна юлда, умартачылык юлында сынап карарга була. Шул максат белән Саранск шәһәрендә умартачылар курсларын тәмамлый һәм умарталык-ларын да оенә алып кайта. Әлбәттә, яна һонәр нечкәлекләренә тошенергә теләсә кемгә дә жинел булмый, ана да авырга туры килә. Тик донья игелек-ле кешеләрсез тvгел: кинәшчеләр дә, ярдәмчеләр дә табыла. Әле дә Альберт Равил улы vз тәжрибәсе белән уртаклашкан умартачылар жәмгыяте рәисе С.В.Юматов, курсларда укыткан укытучы Д.В.Враскинны рәхмәт сvзләре белән искә ала. Тагы хайваннар авыруларына каршы корәш буенча Ләмберә станциясе ветеринария табибы Ф.П.Шлепаев та зур практик ярдәм кvрсәтә. Эш акрынлап жайга салына. Менә бvген дә кирәкле тәжрибә һәм белем туплаган А.Р.Батршин умарталыгын кинәйтvне планлаштыра. Ул язмышына йогынты ясаган һәм

анын тамырларын искә тошергән кешегә бик тә рәхмәтле.
Нәтижәдә, кыскартуга әләгеп, Альберт Равил улы Батршин бабасынын бабасы белән әтисенен һонәрен дәвам итәргә, умартачылык белән шогыльләнергә карар итә һәм яшь умартачы барлык авырлыкларны жинә-жинә барысын да булдыра. Язманын топ герое vрнәгендә хәтта катлаулы тормыш ситуациясеннән дә чыгу юлларын табарга момкин булуын vз кvзләрен белән кvреп була.

**Н.ХӘЛИЛ әзерләде**